КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2021 ел, 6 сентябрь г.Казань № 819

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «2021 елда Татарстан Республикасы территориясендә танылган татар эшлекләре цитаталарын баннерларда урнаштыруга бәйле чыгымнарны каплауга Татарстан Республикасы бюджетыннан юридик затларга субсидияләр бирү тәртибен раслау турында» 2021 ел, 15 июнь, 454 нче карары белән расланган «2021 елда Татарстан Республикасы территориясендә танылган татар эшлекләре цитаталарын баннерларда урнаштыруга бәйле чыгымнарны каплауга Татарстан Республикасы бюджетыннан юридик затларга субсидияләр бирү тәртибенә үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «2021 елда Татарстан Республикасы территориясендә танылган татар эшлекләре цитаталарын баннерларда урнаштыруга бәйле чыгымнарны каплауга Татарстан Республикасы бюджетыннан юридик затларга субсидияләр бирү тәртибен раслау турында» 2021 ел, 15 июнь, 454 нче карары белән расланган «2021 елда Татарстан Республикасы территориясендә танылган татар эшлекләре цитаталарын баннерларда урнаштыруга бәйле чыгымнарны каплауга Татарстан Республикасы бюджетыннан юридик затларга субсидияләр бирү тәртибенә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

4 пунктның беренче җөмләсендә татар текстында «башкарыла» сүзе алдына «елга бер тапкыр» сүзләрен өстәргә;

13 пунктның өченче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«субсидиянең иң чик күләме, аның максатчан билгеләнеше;»;

18 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«18. Килешү төзү өчен әлеге Тәртипнең 3 пунктында күрсәтелгән максатларга субсидия алучыга бирелә торган субсидиянең иң чик күләме (С) (сумда) түбәндәге формула буенча билгеләнә:

$$С = З_1 + З_2 + ... + З_n + Z,$$

монда:

$З_1, З_2, ..., З_n$ – агымдагы финанс елында баннерларда урнаштыру өчен субсидия алучы тарафыннан әлеге Тәртипнең 17 пунктында күрсәтелгән юнәлешләр буенча планлаштырыла, Агентлык тарафыннан тарафыннан бердәй (бертөрле) товарлар, эшләр, хезмәт күрсәтүләрнең базар бәяләре турындагы мәгълүматны, шул исәптән дәүләт статистикасы органнарында, шулай ук массакүләм мәгълүмат чараларында һәм махсус әдәбиятта (җитештерүчеләрнең һәм тәэмин итүчеләрнең «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтларын кертеп) булган җитештерүчеләрнең бәяләре турындагы, бәяләр дәрәҗәсе турындагы мәгълүматны анализлаудан гыйбарәт чагыштырма базар бәяләре (базар анализы) ысулы белән билгеләнә торган чыгымнар (штаттагы һәм штаттан тыш хезмәткәрләрнең эш хакын түләүдән һәм хезмәте өчен түләү буенча түләүләргә исәпләүләрдән тыш) суммасы;

Z – баннерларда урнаштыруда катнашучы штаттагы һәм штаттан тыш хезмәткәрләрнең агымдагы финанс елында субсидия исәбеннән капланырга тиешле эш хакын тәүләүгә чыгымнар һәм хезмәте өчен түләү буенча түләүләргә исәпләүләр; алар хезмәткәрләрнең исәп-хисап саныннан, исәп-хисап вазыйфаи окладларыннан, вазыйфаи окладка ай саен бирелә торган өстәмә түләүләрдән, стимуллаштыра торган түләүләрдән, шулай ук расланган штат расписаниесе нигезендә Россия Федерациясе законнарында каралган башка түләүләрдән чыгып билгеләнә.»;

түбәндәге эчтәлекле $18^1$ пункт өстәргә:

«$18^1$. Хисап чоры өчен бирелә торган субсидия күләме ($С_m$) (сумда) түбәндәге формула буенча билгеләнә:

$$С_m = З_1 + З_2 + ... + З_n + Z,$$

монда:

$З_1, З_2, ..., З_n$ – хисап чоры өчен баннерларда әлеге Тәртипнең 17 пунктында күрсәтелгән юнәлешләр буенча Агентлык тарафыннан тарафыннан бердәй (бертөрле) товарлар, эшләр, хезмәт күрсәтүләрнең базар бәяләре турындагы мәгълүматны, шул исәптән дәүләт статистикасы органнарында, шулай ук массакүләм мәгълүмат чараларында һәм махсус әдәбиятта (җитештерүчеләрнең һәм тәэмин итүчеләрнең «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтларын кертеп) булган җитештерүчеләрнең бәяләре турындагы, бәяләр дәрәҗәсе турындагы мәгълүматны анализлаудан гыйбарәт чагыштырма базар бәяләре (базар анализы) ысулы белән билгеләнә торган чыгымнар (штаттагы һәм штаттан тыш хезмәткәрләрнең эш хакын түләүдән һәм хезмәте өчен түләү буенча түләүләргә исәпләүләрдән тыш) суммасы;

Z – хисап чоры өчен баннерларда урнаштыруда катнашучы штаттагы һәм штаттан тыш хезмәткәрләрнең субсидия исәбеннән капланырга тиешле эш хакын тәүләүгә чыгымнар һәм хезмәте өчен түләү буенча түләүләргә исәпләүләр; алар хезмәткәрләрнең исәп-хисап саныннан, исәп-хисап вазыйфаи окладларыннан, вазыйфаи окладка ай саен бирелә торган өстәмә түләүләрдән, стимуллаштыра торган түләүләрдән, шулай ук расланган штат расписаниесе нигезендә Россия Федерациясе законнарында каралган башка түләүләрдән чыгып билгеләнә.

Хисап чоры булып әлеге Тәртипнең 3 пунктында күрсәтелгән максатлар өчен субсидия алучының чыгымнары барлыкка килгән субсидия бирү елының кварталы тора.

Субсидия аны алучыга килешүдә каралган сумма чикләрендә бирелә.».

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин